СОВЕТ ЗАИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

09.12.2024 г. Заинск № 363

**Зәй муниципаль районы Советының 2018 елның 13 апрелендәге 280 номерлы «Муниципаль хезмәткәрләр булмаган белгечләргә һәм Зәй муниципаль районы җирле үзидарә органнарында эшләүчеләргә хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турындагы Нигезләмә хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында»**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 1998 елның 31 июлендәге 145-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Зәй муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советы

## КАРАР ИТТЕ:

1. Зәй муниципаль районы Советының 2018 елның 13 апрелендәге 280 номерлы «Муниципаль хезмәткәр булмаган белгечләрнең һәм Зәй муниципаль районы җирле үзидарә органнарындагы эшчеләрнең хезмәтенә түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмә турында» карары белән расланган муниципаль хезмәткәрләр булмаган белгечләргә һәм Зәй муниципаль районы җирле үзидарә органнарындагы эшчеләргә хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары хакындагы Нигезләмәгә (Зәй муниципаль районы Советының 27.08.2020 №555, 27.12.2021 №192, 29.09.2022 №235, 18.11.2022 № 245, 13.06.2024 № 334 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.2 пунктта «13323 сум» сүзләрен «13990 сум» сүзләренә алмаштырырга.

2. Зәй муниципаль районы җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә штат расписаниеләренә һәм локаль актларга тиешле үзгәрешләр кертергә.

3. Зәй муниципаль районы Советының оештыру бүлегенә әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) бастырып чыгарырга һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Зәй муниципаль районы Башлыгы урынбасары П. С. Уразайкинга йөкләргә.

**Совет Рәисе** **Р.Г. Кәримов**